РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«4» февраль 2021 ел г. Альметьевск № 186

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Мәктәпкәчә мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү эшен оештыру турында» 2021 елның 13 гыйнварындагы 09/13-09/49 номерлы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хаты нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы карарына түбәндәге (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 02 октябрендәге 3737 номерлы, 2013 елның 04 октябрендәге 3757 номерлы, 2014 елның 14 мартындагы 726 номерлы, 2015 елның 09 ноябрендәге 1290 номерлы, 2016 елның 31 маендагы 1147 номерлы, 2018 елның 05 февралендәге 186 номерлы, 2019 елның 11 сентябрендәге 1655 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) үзгәрешне кертергә:

«1 нче кушымтаның «Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе» 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.1.11 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.1.11. Социаль ярдәм чараларын алучыларның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

Зак. № 305-2000

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов